| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.09.2022 ел Баулы шәһәре №194

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 168 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 168 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

2 "Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты" бүлегендә:

2.5.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле 8) һәм 9) пунктчалар өстәргә:

«8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинага мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;

9) җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә мөрәҗәгать итүченең биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү факты билгеләнү турында суд карары (мөрәҗәгать итүче паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза

биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта).»;

2.6.1. пунктта:

9) пунктчада «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 11) пункт өстәргә:

«11) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинага мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ - Баулы муниципаль районы башкарма комитеты»;

2.8.2. пунктында:

2) пунктчага түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;»;

4) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Установить, что действие подпункта 9) пункта 2.6.1. настоящего постановления вступает в силу с 1 января 2023 года.

«4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның өч тапкыр сайлаудан баш тартуы, яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, йә, гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуы һәм җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очраклары саны барлыгы өчкә тигез булса;».

2.6.1. пунктының 9) пунктчасының гамәлдә булуы әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсешке буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы — И.И. Хөснуллина